**2021 нче елның 12 нче мартында** Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятендә Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирүче уку йортлары студентлары арасында Республика күләмендә “Татар кызы” бәйгесе үткәрелде. Кызларга бәяне мәртәбәле жюри әгъзалары бирде. Алар арасында: *Идрисова Кадрия Раес кызы* – Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмалары җитәкчесе, региональ “Ак калфак” татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе; *Кашапова Рәмзия Әнвәр кызы* – “Сөембикә” журналының директор урынбасары; *Вил Нургали улы Усманов* – җырчы, композитор, Татарстанның халык артисты; *Исмәгыйлев Рәдиф Миннехан улы* – Россия күләмендә “Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы” бәйгесе лауреаты; *Таҗиев Дамир Гыйлемшаех улы* – дөньяда бердән-бер булган “Әлифба” музее җитәкчесе.

Бәйгедә беренче этапны лаеклы рәвештә җиңеп чыккан 11 кыз көч сынашты. Алар түбәндәге номинацияләрдә җиңү яулады:

**“Зирәк кыз”** номинациясе – Казан педагогия көллияте студенты **Абдрахманова Чулпан Рәфис кызы**;

**“Ягымлы кыз”** номинациясе – “Кукмара аграр көллияте” студенты **Мусина Илсинә Алмаз кызы;**

**“Уңган кыз”** номинациясе – «Әлмәт политехника көллияте» студенты **Камалтдинова Алия Наил кызы**;

**“Сөйкемле кыз”** номинациясе – “Владимир Лушников исемендәге Казан нефть һәм химия көллияте” студенты **Абдерәкыйпова Румия Шамил кызы;**

“**Тамашачы мәхәббәтен яулаган кыз”** номинациясе – Казан төзелеш көллияте студенты **Шәрипова Зилә Илдус кызы**;

**“Җитез кыз”** номинациясе – “Арча аграр-сәнәгать һөнәр көллияте” студенты **Сәмигуллина Зөлфия Мотыйгулла** кызы;

***“Иҗади кыз”*** номинациясе – М.Җәлил исемендәге Минзәлә педагогоия көллияте студенты **Талипова Гөлнара Нурсаяф** кызы;

**“Иң ихлас кыз”** номинациясе – «Казан технология һәм дизайн көллияте» студенты **Мөхәмәдуллина Эльвина Валерий** кызы;

**“Иң зур ачыш”** номинациясе – «Түбән Кама педагогика көллияте» студенты **Медведева Алинә Иван кызы**;

**“Зыялы кыз”** номинациясе – Арча педагогия көллияте студенты **Әхмәтҗанова Адилә Роберт кызы;**

***“Максатчан кыз”*** номинациясе – Казан энергетика көллияте студенты **Хөсәинова Рәзилә Ренат кызы.**

Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирүче уку йортлары студентлары арасында Республика күләмендә үткәрелгән “Татар кызы” бәйгесендә **3 урын** Казан төзелеш көллияте студенты **Шәрипова Зилә Илдус кызына, 2 урын** М.Җәлил исемендәге Минзәлә педагогоия көллияте студенты **Талипова Гөлнара Нурсаяф** кызына, **1 урын** «Казан технология һәм дизайн көллияте» студенты **Мөхәмәдуллина Эльвина Валерий** кызына бирелде.

Җюри әгъзалары бер тавыштан бәйгедә иң зур балл җыйган Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте студенты Әхмәтҗанова Адилә Роберт кызын Гран-прига лаек дип тапты һәм Бөтендөнья татар конгрессының махсус бүләген тапшырды. Кызларның һәрберсенә дипломнар, Бөтендөнья татар конгрессы, “Сөембикә” журналы, “Ләйсән” чәчәк кибете һәм төп спонсорыбыз “Кукмара металл савыт-саба заводы” ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан әзерләнгән истәлек бүләкләре бирелде.